ММБДУ №82 “Көнбагышкай”

катнашбалаларбакчасы

Логопед киңәшләре (ата-аналарга)

# Авазларныдөрес
# әйтергә өйрәник

Укытучы-логопед:

Миндиярова Г.Р.

ЯР ЧАЛЛЫ

2016 ел

Авазларны дөрес әйтергә өйрәник

“Сөйләмнең аваз культурасы” дигән төшенчә бик киң тармаклы. Ул үз эченә аңгырашлы сөйләмне (ягъни аваз әйтелешен, дикцияне) характерлый торган әйтелеш сыйфатларын (интонация, темп), алар белән бәйләнешле сәнгатьлелекнең хәрәкәт белән туры килүен (мимика, ишарә), шулай ук аралашу культурасы элементларын ала. Аваз культурасының тцзелмщ компонентлары – сөйләм кабул итү сәләте һәм сөйләм вакытындагы сулыш – аңгырашлы сөйләм барлыкка килүгә төп шарт булып торалар.

Тикшеренүләр шуны күрсәтә: мәктәпкәчә яшьтәге балалар аерым авазларны дөрес әйтмиләр. Моннан тыщ, күп кенә балалар кайбер авазларны йә төшереп калдыралар, өә урыннарын алмаштырып әйтәләр. Кайбер балаларның сөйләме тиз һәм аңлаешсыз була. Мондый сөйләм вакытында бала авызын тиешенчә ачмый, авазлар артикуляциясе көчсез. Бу – сөйләм органнарынын акрын үсеше белән аңлатыла. Сөйләгәндә вак мускуллар хәрәкәтләренең төгәл һәм тиз үтәлүе бик әһәмиятле. Мондый сыйфатлар тора-бара формалаша. Бала сөйләгәндә өзек-өзек, шаулы, туктаусыз сулыш ала. Гадәттә бу үзенчәлекләр кече яшьтәге мәктәп балаларына да хас.

Авазларны әйткәндәге җитешсезлекләр балага начар тәэсир итәләр: ул үз эченә йомыла, кырыслана, тынычсызлана, аның кызыксынучанлыгы кими, бу, үз чиратында, акыл ягыннан артта калуга китерергә мөмкин.

Шуңа күрә балалар бакчасында түбәндәге фонетик нормаларны үзләштерү күздә тотыла:

1. Сүздәге авазларны тыңлаучы җиңел аера алырлык дәрәҗәдә ачык һәм дөрес итеп әйтү, ягъни [О] (тор) - [О] (кино), [Ы] (сыр) – [Ы] (сыр-ашамлык), [Э] (Энҗе) - [Э] (экран), [В] (таwык) - [В] (вагон), [КЪ] (къаты) –[К](киртә), [ГЪ](Гъата) - [Г] (гөл) һәм башка шундый охшаш авазлар буталмаслык итеп сөйләү.

2. Сүзләрне орфоэпик яктан дөрес әйтү:

а) авазларны чиратлаштыру(бәбкә – бәпкә, актив-актиф);

б) ассимиляцияләү (умбер, көмбагыш, умбиш, тоссыз, сүссез);

в) иренләштерү (бороч, төтөн, көтөп);

г) дөрес басым белән әйтү: өстә-өстә, үтә-үтә, батыр-бытыр һ.б. Дөрес әйтмәү сүзнең мәгънәсен боза, аңлауны читенләштерә.

3. Сөйләмнең тавыш көчен, темпын, тонын, интонацияне (аһәңне), дикцияне, басымнарны, паузаларны, үз мөнәсәбәтен һәм, гомумән, сөйләм тою зирәклеген булдыру. (Яңгыр ява. Яңгыр ява? Яңгыр ява! Яңгыр ява...)

Аваз – минималь таркалмас сөйләм берәмлеге ул. Авазларны дөрес әйтү балаларның сөйләм органнары эшчәнлегенә бәйле. Шуңа күрә, сөйләм органнары хәрәкәтләрен камилләштерү өчен, барлык төркемнәрдә дә артикуляциягимнастикалары үткәрәләр. Өйрәнелгән сузык һәм тартык авазларны ачык, төгәл итеп әйтүдә балалар белән көндәлек эш алып барырга кирәк. Дикциягә килгәндә, дикция – сүзләрне һәм сүзләр тезмәсен аңлаешлы, ачык итеп әйтү ул. Дикция өстендә эш балалар бакчалары өчен программалар нигезендә икенче кечкенәләр төркеменнән башлап

барыла (гадәттә җыр һәм шигырьләр уку процессы нигезендә). Ә зурлар төркемендә аерым методлар һәм өйрәтү алымнары кулланыла.

Кайбер очракларда бала барлык авазларны ачык итеп әйтә, дикциясе яхшы, ләкин аерым сүзләрне әйткәндә хаталар җибәрә. Тәрбиячеләр балаларның сүзләрне әйтүдәге типик үзенчәлекләрен белергә тиеш: кече яшьтә балаларга сүзләрне кыскарту, авазларның һәм иҗекләрнең урыннарын алмаштыру, төшереп калдыру, авазлар өстәү хас. Бу үзенчәлекләрне белү балаларның сүзләрне әйтүдәге хаталарын тизрәк төзәтергә ярдәм итә.

Орфоэпиягә килгәндә, орфоэпия – әдәби әйтелеш кагыйдәләренең җыелмасы ул. Орфоэпия нормалары телнең фонетик системасын, шулай ук аерым сүзләрнең һәм сүзтезмәләрнең әйтелешен, грамматик формаларны үз эченә ала. Шуңа күрә, әйтелеш формалашсын өчен, уңайлы шартлар тудырырга кирәк.

Кече яшьтә бала әйтелеш нормаларын практик рәвештә үзләштерә. Тәрбияче балаларга телдән сөйләү үрнәкләрен бирергә тиеш.

Уртача тизлектәге, ритмдагы, уртача көчтәге һәм югарылыктагы сыйфатлары сөйләмдә җиңел кабул ителә. Шул ук вакытта тавыш сыйфатлары һәм сөйләмнең тизлеге кучмә һәм сыгылмалы булырга тиеш, ягъни пышылдап та, көчле тавыш белән дә, тиз дә сөйли белергә кирәк.

Балалар, бигрәк тә кече яшьтәге балалар, кызу сөйләшәләр, урынсыз һәм кыска паузалар ясыйлар. Тәрбияче аларны ашыкмыйча, ритмик сөйләшергә, фраза азагында туктарга, фикергә тиешле интонация бирергә өйрәтергә тиеш.

Тәрбияченең бурычы – балаларга сөйләм вакытындагы сулыш җитешсезлекләрен җиңәргә ярдәм итү, дөрес диафрагмаль сулыш алырга өйрәтү. Төп игътибар сөйләм процессында сулыш чыгаруның дәвамлылыгына, көченә һәм фразаны әйтер алдыннан шаусыз тирән сулыш алуга юнәлтелергә тиеш.

Балаларга авазларны өйрәтү эшчәнлеген комплекслы алып барырга кирәк. Сөйләм шөгыльләренә аеруча игътибарлы булу таләп ителә. 3-5 минутка кадәрле артикуляция гимнастикаларын индивидуаль эш итеп тә планлаштырырга мөмкин. Без моны хезмәтнең эчтәлегендә I (өлешчә уздырыла), II (өлешчә уздырыла), III (тулысынча уздырыла) дип билгеләдек. Чөнки авазларны дөрес әйтергә өйрәтүнең бу өлешләрен барлык балалар белән берьюлы үткәрү уңай нәтиҗәләр бирми. Балалар авазларны дөрес әйтү күнекмәләрен үзләштереп бетергәч кенә, шөгыль тулысынча уздырыла.

Айга ике тапкыр тулысынча сөйләмнең аваз культурасына багышланган комплекслы шөгыль үткәрергә була. Мондый шөгыльләрне бигрәк тә икенче кечкенәләр төркемнәрендә үткәрергә кирәк, чөнки бу төркемнәрдә авазлар әйтелеше буенча эш күләме бик югары тора.

Мондый шөгыльдә вакытның күп өлеше бер авазны яки охшаш авазларны әйтүгә юнәлтелә. Калын һәм нечкә сузыкларны [а] - [ә], [ы] - [и], [у] - [ү] һәм тел арты, увуляр тартыкларны [а] - [къ], [к], [гъ], [г], [х], [һ] чагыштырып әйтергә кирәк. Мондый шөгыльләр балаларга туган телнең барлык авазларын үзләштерүдә ярдәм итә. (Бу процесс 5 яшькә тәмамланырга тиеш).

Комплекслы эшнең башка формалары да зур әһәмияткә ия. Алар шөгыльдән тыш вакытта, сүзле, җырлы һәм хәрәкәтуртанчыларле уеннарда, балалар иртәләрендә алып бырылалар.

Икенче кечкенәләр һәм уртанчылар төркемнәрендә сөйләмле гимнастика бик нәтиҗәле (иртәнге гимнастика ахырында 1-2 минут артикуляцион күнегүләр үткәрү, атнага 2-3 тапкыр). Мәсәлән:

"Нинди тәмле туңдырма!" күнегүе.

Тәрбияче туңдырма ашаучы балаларның рәсемнәрен күрсәтә (рәсемдә туңдырманы телләре белән ялау һәм өске иреннәренә тигән туңдырманы телләре белән оста итеп ялау хәрәкәтләре күрсәтелгән).

- Балалар, әйдәгез, сез дә туңдырма ашау хәрәкәтләрен күрсәтегез (балалар туңдырма ялау хәрәкәтләре ясыйлар).
  Сезнең өске иреннәрегезгә туңдырма тигән, әйдәгез, аларны чистартыйк. Оста итеп алыйк (тәрбияче күрсәтә).
  Ә хәзер сез ялап күрсәтегез. Бик яхшы.
  Методик күрсәтмә. Тел өскә һәм аска хәрәкәт иткәндә, ияк һәм иреннәр хәрәкәтсез торалар.
  Төркемнәр белән дидактик уеннар, мәзәкләр, тизәйткечләр тәрбиячегә уңайлы вакытта үткәрелә.
  Сөйләмнең аваз культурасын тәрбияләүгә нинди методлар хас соң? Болар – дидактик уеннар ("Кемнең өе?", "Оркестр"), хәрәкәтле һәм әйлән-бәйлән уеннары (текст белән) – "Атлар, "Ак калач". Балаларга биремнәр кертелгән дидактик хикәяләр бик файдалы. Биремнәр булып, мәсәлән, авыр аваз кергән сүзләрне кабатлау, тавыш корылышын үзгәртү тора.
  Икенче кечкенәләр һәм уртанчылар төркемнәрендә рәсемнәр күрсәтергә һәм уеннар, уенчыклар ярдәмендә инсценировка оештырырга мөмкин.
  Икенче кечкенәләр төркемнәрендә авазны яки авазлар тезмәсен образлы әйтү еш кулланыла (мәсәлән, ззз – черки тавышы, туп-туп – кәҗә бәтие сикереп йөри). Бу төркемнәрдә авазларны әйтүдә сөйләм органнары хәрәкәтен күзәтү, күрсәтү һәм аңлату еш кына уенлы сюжетка кертелә."Шаян тел" әкияте.
  Актив алым булып хор белән һәм индивидуаль кабатлаулар тора. Бу эш төрен комплекслы шөгыльләрдә 2-10 минут, шулай ук шөгыльдән тыш та планлаштырырга мөмкин.
  Авазларны чиста, дөрес әйтү күнекмәләрен үстерүдә үрнәк сөйләмнән файдаланырга кирәк. Бу факторны шөгыльләрдә генә түгел, ә уеннар, күнегүләр вакытында да файдалынырга мөмкин. Чөнки уеннарга барлык балалар да тартыла.
  Җавапка бәя бирү, хаталарны күрсәтү һәм төзәтү традицион алымнардан санала. Шул ук вакытта еш төзәтүләрдән, әйтеп җибәрүләрдән сакланырга кирәк, чөнки алар баланы көйсезләндерәләр.
  Шөгыльләрдә махсус алымнарның берсе – образлы физкультурапаузасы. Биредә балаларның хәрәкәтләре кирәкле авазларны яки авазлар тезмзсен әйтү белән аралаша. Шул ук вакытта мондый паузалар ял да, өйрәтү материалын ныгыту да булып торалар.
  3-4 яшьлек балалар артикуляциябилгеләре гади булган [а],[ә], [у], [ү], [о], [ө], [б] [п],[в], [w], [ф] авазларын тизрәк үзләштерәләр.

4-5 яшьтә артикуляция билгеләре катлаулырак булган [д],[т], [н], [с], [з] авазларын, ә 5-6 яшьлек балалар сөйләмдә соңрак барлыкка килә торган [р],[ң], [къ], [гъ], [һ] авазларын тизрәк үзләштерәләр.

Авазларны дөрес әйтергә өйрәтү өч этаптан тора:

1) авазны әйткәндә сөйләм аппараты органнарын дөрес хәрәкәтләндерү күнекмәләре бирү;

2) аерым авазны әйтүне ачыклау;

3) авазларны сүзләрдә, сөйләмдә ныгыту.

Без бер авазны өйрәтү процессының типик төзелешен түбәндәгечә бирдек:

1) аваз артикуляциясен күрсәтү, аңлату, тәрбияченең күп тапкырлар авазны әйтеп күрсәтүе;

2) балаларның аерым авазны сөйләм вакытындагы сулыш һәм сөйләмнең сәнгатьлелеге белән бер үк вакытта әйрәнүе;

3) иҗекләп әйттерү;

4) авазны сүзләрдә һәм фразалы сөйләгәндә әйтүгә күнегүләр ( экиятләрне, мәзәкләрне, тизәйткечләрне, хикәяләрне сәхнәләштерү, дидактик, сүзле һәм хәрәкәтле уеннар, шигырьләр уку).

Шулай итеп, авазларны дөрес әйтү буенча эш бербөтен система булып торырга тиеш. Ул баланың бакчага килгән беренче көннәреннән ук башлана. Олыларның махсус игътибарыннан башка, балаларда сөйләмнең авазлар ягы үсеше тоткарлана, тискәре сөйләм гадәтләре барлыкка килергә мөмкин, ә аларны төзәтүе бик авыр.

Балалар бакчасында авазларны әйтергә өйрәтүне дөрес оештыру, эзлекле, нигезле, бәйләнешле алып бару бик мөһим.